**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 17 август № 603

г. Казань

«Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен» республика премияләре турында

«Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында» 2015 елның 16 гыйнварындагы № 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, җәмәгать тәртибен саклауны гамәлгә ашыручы халык дружиналары әгъзаларын бүләкләү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен» республика премиясе турында нигезләмәне расларга.

2. «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен» республика премиясен бирү комиссиясе вазыйфаларын Татарстан Республикасында халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү буенча республика штабы гамәлгә ашыра, дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән чараларны тормышка ашыру фаразланган максатларга тиешле финанс елына һәм планлаштырылган чорга Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованияләре кысаларында гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары А.В.Песошинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\603.docx